ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 27 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 1; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2018, № 54 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 3 өлешендә «Муниципаль регистрга кертү өчен муниципаль норматив хокукый акт кергән көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләреннән соң «, ә әлеге Законның 4 статьясындагы 1 өлешенең икенче абзацында каралган очракта аның «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) көненнән» сүзләрен өстәргә;

2) 4 статьяда:

а) 1 өлешкә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Муниципаль норматив хокукый акт кабул ителгән (чыгарылган) көннән алып 10 эш көне эчендә «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми бастырып чыгарылган (халыкка игълан ителгән) очракта, аны вәкаләтле органга җибәрү таләп ителми.»;

б) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль норматив хокукый акт белән бер үк вакытта муниципаль берәмлек башлыгы муниципаль норматив хокукый актның барлык рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турындагы белешмәләрне дә җибәрә.

Муниципаль норматив хокукый акт әлеге статьяның 1 өлешендәге икенче абзацы нигезендә вәкаләтле органга җибәрелмәгән очракта, муниципаль норматив хокукый акт «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми бастырып чыгарылган (халыкка игълан ителгән) көннән алып 10 эш көне эчендә, муниципаль норматив хокукый актның барлык башка рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турындагы белешмәләр күрсәтелгән вакыт эчендә әлеге порталга урнаштырылмаса, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан мондый белешмәләр дә җибәрелә.

Муниципаль норматив хокукый акт әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вакыт чыкканнан соң рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) очракта, рәсми басылып чыгу (халыкка игълан ителү) чыганаклары һәм даталары турындагы белешмәләр, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) басылып чыгу (халыкка игълан ителү) турындагы белешмәләрдән тыш, аның рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән алып 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан вәкаләтле органга җибәрелә.

Муниципаль берәмлек башлыгы вәкаләтле орган соравы буенча 15 көн эчендә муниципаль норматив хокукый актның рәсми басылып чыгу чыганаклары булып торучы басма чаралардагы публикацияләренең үзе раслаган күчермәләрен вәкаләтле органга җибәрә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ / АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 09 декабрь
№ 97-ТРЗ